ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14 ноябрь, 2025 ел № 2/11

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында

Яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен хокукый җайга салу, яшьләр проблемаларын хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләү, яшьләргә хокукый эшчәнлек күнекмәләрен үзләштерү һәм шәһәр яшьләренә Россия яшьләр парламентаризмы хәрәкәтендә катнашу өчен шартлар тудыру буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы эшчәнлегенә ярдәм итү максатларында

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы каршында Яшьләр парламенты оештырырга.
2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
3. Гамәлдәге Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы каршындагы Яшьләр парламенты яңа чакырылыш Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы каршындагы Яшьләр парламентының беренче утырышы көненнән үз эшчәнлеген туктата, күрсәтелгән көнгә кадәр уз исемен һәм вәкаләтләрен саклый дип билгеләргә.
4. Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында» 2020 елның 11 августындагы 41/15 номерлы Карарын көчен югалткан дип танырга, «Челнинские известия» газетасының 2020 елның 14 августындагы 59, «Шәһри Чаллы» газетасының 2020 елның 14 августындагы 59 саннарында басылган.

5. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының мәгариф, мәдәният, милли мәсьәләләр, яшьләр эшләре һәм спорт буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
2/11 Карарына
кушымта
14 ноябрь, 2025 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы каршындагы Яшьләр парламенты (алга таба – Яшьләр парламенты) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы (алга таба — Шәһәр Советы) эшчәнлегенә яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен норматив-хокукый җайга салу, яшьләр проблемаларын хәл итү буенча тәкъдимнәр эшләү, яшьләрнең хокукый иҗат эшчәнлеге күнекмәләрен үзләштерүе өчен шартлар тудыру һәм Яр Чаллы шәһәре яшьләренең Россия яшьләр парламентаризмы хәрәкәтенә катнашуын тәэмин итү максатыннан оештырыла.

2. Яшьләр парламенты Шәһәр Советы каршындагы киңәшмә һәм консультатив орган булып тора һәм үз эшчәнлеген Яшьләр парламенты тарафыннан расланган әлеге нигезләмә нигезендә иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашыра.

3. Яшьләр парламенты конкурс нәтиҗәләре нигезендә 2 ел срокка формалаша.

2 бүлек. Яшьләр парламентының төп бурычлары

4. Яшьләр парламентының төп бурычлары:

1) яшьләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагыла торган муниципаль норматив хокукый актлар эшләгәндә яшь гражданнарның инициативаларын тәкъдим итүгә ярдәм итү;

2) яшьләрнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре өлкәсендә норматив-хокукый актларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү;

3) Шәһәр Советының яшьләр хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы норматив-хокукый актлар проектларын карауга әзерләү эшчәнлегендә катнашу;

4) яшьләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы муниципаль хокукый актларга мониторинг ясауда катнашу;

5) Яр Чаллы шәһәре территориясендә яшьләрнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре турындагы законнарның үтәлешенә җәмәгать контролен гамәлгә ашыру;

6) яшьләр даирәсендә яшьләрнең хокукый культурасын һәм юридик белемен күтәрүгә һәм актив гражданлык позициясен формалаштыруга юнәлдерелгән аңлату эшләре үткәрү;

7) дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеге хакында яшь гражданнарның фикерен өйрәнү;

8) халыкара, гомумроссия, төбәкара, төбәк һәм җирле яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән иҗтимагый әһәмиятле идеяләргә теләктәшлек күрсәтү һәм тәҗрибә уртаклашу максатларында хезмәттәшлек итү;

9) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты белән хезмәттәшлек итү;

10) Яшьләр парламентын оештыру максатларына туры килә торган һәм законнарга каршы килми торган башка мәсьәләләрне хәл итү.

3 бүлек. Яшьләр парламентын оештыру тәртибе һәм аның составы

5. Яшьләр парламенты әгъзасы буларак, үз вәкаләтләре расланган көнне кертеп, 18 яшьтән 35 яшькә кадәр булган, Яр Чаллы шәһәре территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары Яшьләр парламенты әгъзалары була ала.

6. Яшьләр парламенты әгъзасы була алмый:

1) чит дәүләт гражданлыгы (подданство) яки яшәүгә рөхсәт, яисә чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булган зат;
2) гамәлдән чыгарылмаган яки кире алынмаган хөкем ителүе булган зат;

3) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексының 20.3 һәм 20.29 статьяларында каралган административ хокук бозулар кылган өчен административ җаваплылыкка тартылган (җәлеп ителгән) зат;

4) әлеге нигезләмәнең 8 пунктында каралган очрактан тыш, башка муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы каршындагы Яшьләр парламенты (советы) әгъзасы булган зат.

7. Яшьләр парламенты конкурс нигезендә 23 кеше санында Яр Чаллы шәһәре яшьләрен тәшкил итүче гражданнардан төзелә.

8. Яшьләр парламенты составына 35 яшькә кадәрге һәм шул сшnout Шәһәр Советы депутатлары кертелергә мөмкин. Депутатны Яшьләр парламентына кертү аның Яшьләр парламентын формалаштыруны оештыру комитетына шәхси гаризасы нигезендә һәм конкурстан тыш гамәлгә ашырыла. Яшьләр парламентына кертелгән депутатлар саны аның гомуми саныннан 10 проценттан артмаска тиеш.

9. Яшьләр парламентының персональ составы әлеге нигезләмәгә кушымта нигезендә конкурс турындагы нигезләмәдә каралган тәртиптә ачык конкурс нәтиҗәләре буенча төзелә.

10. Яшьләр парламентының персональ составы алдагы чакырылыш Яшьләр парламентының карары белән раслана.

11. Яшьләр парламенты әгъзасы вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

1) Яшьләр парламенты составыннан чыгу турында шәхси язма гариза бирү;

2) Яшьләр парламентының рәттән ике яисә аннан күбрәк утырышында нигезле сәбәпсез катнашмау;

3) Яшьләр парламенты әгъзасына карата судның гаепләү хөкеме законлы көченә керү;

4) Яшьләр парламенты әгъзасының законлы көченә кергән суд карары белән хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылуы;

5) Россия Федерациясе гражданлыгын югалту, чит дәүләт гражданлыгын алу яки чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукына ия булу;

6) үлгән яки суд тарафыннан үлгән яки хәбәрсез югалган дип игълан ителгән очракта.

12. Үз кандидатурасын тәкъдим иткән Яшьләр парламенты әгъзасының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, әлеге нигезләмәнең 5 пункты нигезендә, Яшьләр парламенты карары белән Яшьләр парламенты әгъзасы булып иң күп тавыш җыйган кандидат билгеләнә. Күрсәтелгән карар Яшьләр парламенты тарафыннан 10 көн эчендә кабул ителә.

## 4 бүлек. Яшьләр парламенты эшчәнлеген оештыру

13. Яшьләр парламентының беренче утырышы алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты тарафыннан чакырыла. Утырышны алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты рәисе башлый.

14. Беренче утырышта Яшьләр парламенты әгъзалары ачык тавыш бирү белән Яшьләр парламенты әгъзалары арасыннан рәис, рәис урынбасарларын, җаваплы секретарьне сайлыйлар, Яшьләр парламенты Советының санлы составын билгелиләр һәм аның әгъзаларын сайлыйлар, Яшьләр парламенты комиссияләрен төзиләр һәм аларның рәисләрен сайлыйлар. Яшьләр парламенты рәисләренә кандидатлар үз эшчәнлеге программаларын тәкъдим итәргә тиеш.

15. Яшьләр парламенты утырышлары зарурлыктан чыгып, ким дигәнлә кварталга бер тапкыр уздырыла. Утырышта Яшьләр парламенты әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә яртысы катнашса, утырыш тулы хокуклы була.

16. Яшьләр парламенты үз эшчәнлеген гамәлгә ашырганда даими һәм вакытлы комиссияләр, эшче һәм эксперт төркемнәре төзергә хокуклы.

17. Яшьләр парламентын Яшьләр парламенты рәисе җитәкли, аның вәкаләтләре Яшьләр парламенты регламенты белән билгеләнә.

18. Яшьләр парламенты Советы:

1) Яшьләр парламенты һәм аның комиссияләре эшен оештыра һәм координацияли;

2) Яшьләр парламенты регламентын эшли һәм аны Яшьләр парламенты раславына тәкъдим итә;

3) чираттагы елга Яшьләр парламентының эш планнарын эшли һәм аларны Яшьләр парламентына раслауга тәкъдим итә;

4) Яшьләр парламенты регламенты нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

19. Яшьләр парламенты комиссияләре регламентта билгеләнгән функцияләре нигезендә эшчәнлеген оештыра, Яшьләр парламенты утырышларында карау өчен тәкъдимнәр һәм карарлар проектларын әзерли.

20. Яшьләр парламенты карарлары утырышта катнашучы әгъзалар саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

21. Яшьләр парламенты карарлары тәкъдим итү характерында була һәм бәяләмәләр, тәкъдимнәр рәвешендә рәсмиләштерелеп, Шәһәр Советына җибәрелә.

22. Яшьләр парламенты эшчәнлеген оештыру-техник һәм документлар белән тәэмин итү Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге Шәһәр Советы
каршындагы Яшьләр парламенты
турында нигезләмәгә кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге ШәҺәр Советы каршындагы Яшьләр парламентын оештыруга конкурс турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге ШәҺәр Советы каршындагы Яшьләр парламенты (алга таба – яшьләр парламенты) әгъзалыгына кандидатларны сайлап алу буенча ачык конкурс оештыру һәм уздыру тәртибен билгели.

2. Конкурс Яшьләр парламентының персональ составын ачык, тигез мөмкинлекләр һәм яшьләрнең фикерен исәпкә алу принциплары нигезендә формалаштыру максатларында үткәрелә.

2 бүлек. Конкурсны оештыручы

3. Конкурсны оештыру һәм үткәрүне оештыру комитеты (алга таба - комитет) гамәлгә ашыра.

4. Комитет составы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең Шәһәр Советы, алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыручы вәкаләтле органы вәкилләреннән тигезлеге (паритет) нигезендә төзелә.

5. Комитетның персональ составы, шул исәптән аның рәисе Яшьләр парламенты карары белән раслана. Комитет саны так санда булып, 5 кешедән дә ким була алмый.

6. Комитет:

1) конкурсны уздыру графигын һәм регламентын раслый;

2) кандидатлардан гаризалар кабул итә һәм тикшерә;

3) конкурсны үткәрү барышы турында җәмәгатьчелеккә хәбәр итә;

4) тавыш бирүне оештыра;

5) конкурска йомгак ясый һәм Яшьләр парламентына сайланган әгъзаларының йомгаклау исемлеген һәм кандидатларның резерв исемлеген төзи;

6) әлеге нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

7. Комитет утырышы, әгәр анда Комитетның расланган әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы дип санала. Карар утырышта катнашучылар санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, комитет рәисе тавышы хәлиткеч була.

3 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе һәм этаплары

8. Конкурс игълан итү , шул исәптән аны үткәрү сроклары һәм урыны турында карар алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты тарафыннан кабул ителә.

9. Конкурс игълан итү турындагы карар, конкурсны үткәрү шартлары һәм сроклары турындагы мәгълүмат комитет тарафыннан конкурс игълан итү турында карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә шәһәрнең Интернет челтәрендәге мәгълүмати рәсми сайтында урнаштырыла.

10. Конкурста Яшьләр парламенты турындагы нигезләмәнең 5 һәм 6 пунктлары таләпләренә туры килә торган Россия Федерациясе гражданнары катнаша ала.

11. Конкурс этаплап үткәрелә.

12. Конкурсның беренче этабы конкурста катнашырга теләк белдергән гражданнар тарафыннан гаризалар бирүдән гыйбарәт.

13. Гаризалар электрон рәвештә molparlament.nch@mail.ru. электрон почтасына җибәрелә.

14. Гариза составына керә:

1) алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты карары белән билгеләнгән форма буенча шәхси гариза;

2) кандидатның алдагы Яшьләр парламенты карары белән билгеләнгән форма буенча тутырылган анкетасы. Конкурста катнашу өчен үз кандидатурасын тәкъдим иткән гражданның анкетасында әлеге нигезләмәнең 10 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен билгеләргә мөмкинлек бирүче белешмәләр мәҗбүри рәвештә күрсәтелергә тиеш;

3) гражданның шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы.

15. Конкурста катнашу өчен гражданнар гаризалары турыдан-туры комитет тарафыннан кабул ителә.

16. Тапшырылган гаризалар комитет тарафыннан тикшерелә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Комитет гариза кабул итү һәм конкурсның киләсе этабында катнашу өчен рөхсәт алу турында карар кабул итә. Киләсе этапта катнашуга кертелүче Яшьләр парламенты әгъзасына кандидат статусын ала (алга таба - кандидат).

17. Конкурсның икенче этабы Яшьләр парламенты составын оештыру буенча конкурс тавыш бирүенә яшьләрне җәлеп итү буенча кандидатлар катнашында агитация чаралары үткәрүдән гыйбарәт.

18. Кандидат үзен хуплату өчен мөстәкыйль рәвештә законнарга каршы килми торган чаралар үткәрергә хокуклы.

19. Өченче этап кандидатлар өчен тавыш бирү үткәрүдән гыйбарәт.

20. Кандидатлар өчен тавыш бирү Интернет челтәре сайтында https://open.tatarstan.ru/polls башкарыла.

21. Тавыш бирүдә Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче 14 яшьтән 35 яшькә кадәр Россия Федерациясе гражданнары (алга таба - тавыш бирүдә катнашучы) катнашырга хокуклы.

22. Тавыш бирүдә катнашучы кандидатларның чикләнмәгән саны өчен тавыш бирергә хокуклы. Шул ук вакытта кандидат өчен бары тик шәһәр территориясендә яшәүче тавыш бирүдә катнашучы гына тавыш бирергә хокуклы.

23. Тавыш бирүдә катнашучы кандидатлар өчен бер генә тапкыр тавыш бирергә хокуклы.

24. Дүртенче этап конкурсның тавыш бирү нәтиҗәләрен игълан итү һәм бастырудан гыйбарәт.

25. Иң күп тавыш җыйган кандидатлар конкурста җиңүчеләр дип танылa.

26. Тавыш бирү нәтиҗәләре шәһәрнең Интернет челтәрендәге рәсми мәгълүмат сайтында урнаштырыла.